Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
«Ульяновка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены карары

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлегенең Саминовка авылы
торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«11» ноябрь 2019 ел № 1/2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 11 ноябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2020 елда Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең Саминовка авылы торак пункты территориясендә теркәлгән һәм дәими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш, һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Ульяновка, Нагорный, Саминовка, Сосновка, Девичья Поляна торак пунктларында урам утларын монтажлауга, урнаштыруга, ремонтлауга, карап тотуга һәм хезмәт күрсәтүгә, урам утларының бишенче чыбыгын урнаштыруга, урам утларын куллану чыгымнарын түләүгә, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- Ульяновка, Нагорный, Саминовка, Сосновка, Девичья Поляна торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнарына;
- Ульяновка, Нагорный һәм Саминовка торак пунктларында су челтәрләрен реконструкцияләүне проектлаштыруга, су башнялары территориясен, скважиналарны төзекләндерүгә, кулланылган электр энергиясе һәм хезмәтләр өчен чыгымнарны түләүгә;

- "Сирена" тавышлы сөйләшү җайланмасын сатып алуга, урнаштыруга, монтажлауга, карап тотуга һәм хезмәт күрсәтүгә, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

**«ӘЙЕ»** **«ЮК»**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 52 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 29 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 29 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге составына керүче Саминовка авылы торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2020 елда Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең Саминовка авылы торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш, һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Ульяновка, Нагорный, Саминовка, Сосновка, Девичья Поляна торак пунктларында урам утларын монтажлауга, урнаштыруга, ремонтлауга, карап тотуга һәм хезмәт күрсәтүгә, урам утларының бишенче чыбыгын урнаштыруга, урам утларын куллану чыгымнарын түләүгә, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

- Ульяновка, Нагорный, Саминовка, Сосновка, Девичья Поляна торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнарына;

- Ульяновка, Нагорный һәм Саминовка торак пунктларында су челтәрләрен реконструкцияләүне проектлаштыруга, су башнялары территориясен, скважиналарны төзекләндерүгә, кулланылган электр энергиясе һәм хезмәтләр өчен чыгымнарны түләүгә;

- "Сирена" тавышлы сөйләшү җайланмасын сатып алуга, урнаштыруга, монтажлауга, карап тотуга һәм хезмәт күрсәтүгә, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга- карар кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: Ульяновка авылы,. Центральная урамы, 44, Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Ульяновка авыл җирлеге башлыгы: Шәмсетдинов С.З.